**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

2023елның 20 октябре 3381 номер

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Комлы Ковал авыл җирлегенең генераль планы проектын әзерләү турында**

Территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураны үстерү, гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең, юридик затларның һәм гавами-хокукый берәмлекләрнең мәнфәгатьләрен тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 23, 24, 25 статьяларына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9, 10 статьяларына, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставына таянып, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Комлы Ковал авыл җирлегенең генераль планы проектын әзерләүгә түбәндәге составта керешергә:

1) территориаль планлаштыру турында нигезләмә;

2)җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру планлаштырыла торган карта;

3) торак пункт составына керүче торак пунктларның чикләре картасы;

4) торак пунктның функциональ зоналары картасыя.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Комлы Ковал авыл җирлегенең генераль планы проектын әзерләү 100% күләмендә инвестор акчалары хисабына башкарылачак, башкарылган эшләр өчен түләү килешү шартлары нигезендә башкарылачак.

3. Генераль план проектын әзерләү буенча эшләрнең түбәндәге этапларын билгеләргә:

| Этаплар номеры | Эшләр этабы исеме |
|---|---|
| 1 | Генераль план проектын әзерләүгә контракт төзү, техник бирем әзерләү |
| 2 | Генераль план проектын әзерләү |
| 3 | Генераль план проекты буенча гавами тыңлаулар (фикер алышулар) үткәрү |

| | |
|---|---|
| | (шул исәптән гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләү һәм аларның нәтиҗәләре турында бәяләмә) |
| 4 | Генераль план проектына гавами тыңлаулар (фикер алышулар) нәтиҗәләре буенча, кирәк булганда, төзәтмәләр кертү |
| 5 | Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарында генераль план проектын килештерү |
| 6 | Генераль план проектын, ачык тыңлаулар (фикер алышулар) нәтиҗәләре турында бәяләмәне, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының җыелма бәяләмәсен, раслау өчен Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советына җибәрү |

4. Генераль план проектын әзерләү эшләрен Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгына йөкләргә.

5. Әлеге карарны “Кама ягы” («Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы А. П. Карсаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**